| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2019 Казан шәһәре № 5-93/тэ

«Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-100/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2020 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, һәм 2020-2023 елларга җайга салынулы оешманың план буенча кирәкле тулай табышын тәгаенләштереп, 2020-2023 елларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә тарифлар билгеләү турында» 19.12.2018 № 5-100/тэ карарына 1 кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-100/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2019 № 5-93/тэ карары редакциясендә)

## «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Кулланучыларга җибәрелә торган җылылык саклау матдәсенә тарифлар | | | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте | бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 19,04 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 20,11 | - |
| | | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 19,88 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 19,88 | - |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 20,08 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 20,98 | - |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 20,98 | - |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 21,30 | - |
| | | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 21,30 | - |
| | | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 22,16 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге